Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VI-7**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 19 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча әҗәтләрне түләтүгә һәм исәптән чыгаруга карата ышанычсыз дип тану тәртибе турында (җирле бюджетка керем өлешендә)

Муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләүләре буенча әҗәтләрне түләттерү процессын җайга салу, икътисадый, социаль яисә хокукый характердагы сәбәпләр аркасында түләтүгә өметсез (ышанычсыз) дип танылган бурычларны бетерү максатларында, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча әҗәтләрне түләтүгә һәм исәптән чыгаруга карата ышанычсыз дип тану тәртибен (җирле бюджетка керем өлешендә) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2015 елның 19 декабрендәге
VI-7 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча әҗәтләрне түләтүгә һәм исәптән чыгаруга карата ышанычсыз дип тану тәртибе (җирле бюджетка керем өлешендә)**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве буенча арендаторларның икътисадый, социаль яисә юридик характердагы сәбәпләр аркасында түләтү мөмкин булмаган бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә булган аренда түләүләрен вакытында түләмәгән (алга таба - мөлкәт) өчен исәпләнгән пенялар турындагы мәгълүматларны исәпкә алуда реаль чагылыш табу максатларында гамәлдәге кануннар нигезендә эшләнгән,

1.2. Мөлкәт өчен аренда түләүләре буенча бурычлар (әҗәт), шулай ук аренда түләүләрен вакытында түләмәгән өчен (алга таба - бурыч) исәпләнгән пенялар түләтүгә өметсез (ышанычсыз) дип танылa һәм түбәндәге очракларда исәптән чыгарылырга тиеш:

1) юридик зат эшчәнлеген туктату - арендатор, шул исәптән теркәүче орган карары буенча юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан юкка чыгару юлы белән яисә төшереп калдыру юлы белән, шулай ук юридик зат турында мәглүматлар булмау - юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында арендатор;

2) бурычлы дип тану -арендаторны «Банкротлык турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бурычлы кешенең мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән әҗәтләре өлешендә банкрот (бөлгенлеккә төшкән) дип тану;

3) үлем аркасында яисә физик зат - арендаторны үлгән дип игълан итү (варислары булмаган очракта, арендатор вафат булган очракта, шартнамә нигезендә йөкләмәләрне туктату каралган);

4) бурычларын түләттерүдән баш тарткан суд карарының законлы көченә керүе;

5) башкарма производствоны тәмамлау турында һәм башкарма документны түләтү мөмкинлеге булмауга бәйле рәвештә кире кайтару турында суд приставының карары булу;

6) бурычлыны булмаган дип тану.

II. Бурычларны (әҗәтләрне) түләтү һәм исәптән чыгару өчен ышанычсыз (өметсез) дип тану турында карар кабул итү тәртибе

2.1. Бурычларны түләтү һәм исәптән чыгару өметсезлеген тану турындагы карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый акты белән расланган комиссия тарафыннан

кабул ителә (алга таба - Комиссия).

2.2. Комиссия тапшырылган мәгълүматларны карый, аларның дөреслеген тикшерә һәм бурычларны исәптән чыгару турында яисә аларны тапшырганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча аннан баш тарту турында карар кабул итә.

2.3. Комиссия карарлары һәр тиңдәшле арендатор буенча комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

2.4. Комиссия карары беркетмә белән өч нөсхәдә рәсмиләштерелә, алар документларны карауда катнашкан комиссия рәисе һәм аның барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

2.5. Бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз тану Комиссия карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән башкарыла. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кабул ителә.

2.6. Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы, бурыч тулысынча исәптән чыгарылган очракта, бурычларны юкка чыгару өчен нигез булып тора.

## III. Бурычны түләтүгә ышанычсыз дип танып исәптән чыгару өчен кирәкле документлар исемлеге

Бурычны түләтүгә ышанычсыз дип танып исәптән чыгару турындагы карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

3.1. юридик затны - арендаторны бетергән очракта, гамәлдәге законнар нигезендә яисә юридик зат – арендатор турында юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында мәгълүматлар булмаган очракта:

3.1.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр (кушымта №1);

3.1.2. юридик затны - бурычлы-арендаторны бетерү турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр яисә юридик зат турында белешмәләр булмау;

3.2. бурычлы арендаторны “Бөлгенлек (банкротлык) турында” 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип таныган очракта - бурычлының мөлкәте җитмәү сәбәпле түләнмәгән бурыч (әҗәт) өлешендә:

3.2.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.2.2. арбитраж суды тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган бурычлы - арендаторга карата конкурс производствосын тәмамлау турында арбитраж суд билгеләмәсе күчермәләре;

3.2.3. арендатор-бурычлы юридик затны бетерү турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр;

3.3. физик затның үлеме яки суд тарафыннан арендатор үлгән дип игълан ителгән очракта (варислары булмаган очракта, арендатор вафат булган очракта, шартнамә нигезендә йөкләмәләрне туктату каралган):

3.3.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.3.2. арендатор-физик затның үлеме турындагы таныклыкның күчермәләре яки арендатор физик затны үлгән дип игълан итү турындагы суд карарының күчермәсе;

3.3.3. варистан бурычны түләтү мөмкин булмауны раслый торган документ яисә физик затның нәселдәнлек милкенең - үлгән яисә суд тарафыннан үлгән дип игълан ителгән арендаторның дәүләткә күчүен раслаучы документ (варисларның закон буенча да, васыять буенча да варислар булмавын раслаучы тиешле нотариус белешмәләре, варисларның берсе дә мирас итеп алырга хокуклы түгел яки барлык варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яки барлык варислар да мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән);

3.4. закон көченә кергән, бурычны түләтү турындагы таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарткан суд актлары булган очракта:

3.4.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.4.2 закон көченә кергән суд актының күчермәләре, бурычны түләтү турындагы таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында;

3.5. башкарма производствоны тәмамлау турында һәм башкарма документны кире кайтару мөмкин булмауга бәйле рәвештә суд приставы карары булган очракта:

3.5.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.5.2. суд приставының башкарма производствоны тәмамлау һәм башкарма документны кире кайтару турындагы карары;

3.6. бурычлы-арендаторны булмаган (юк) дип таныган очракта:

3.6.1. исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында белешмәләр;

3.6.2. теркәлү урыны һәм оешманың - арендаторның урнашу урыны турында мәгълүмат булмау турында салым органы документы;

3.6.3. күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнан милек хокукында арендаторга караган күчемсез мөлкәт турында мәгълүмат булмау хакында белешмәләр;

3.6.4. милек хокукында арендаторга караган күчемле мөлкәтнең булмавы турында белешмәләр.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Бурычны исәптән чыгару белән бәйле үзгәрешләр бурычларны исәптән чыгару турында карар кабул ителгән айдан соң килүче айның 1 нче числосына кертелә.

4.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль мөлкәтне һәм җир

кишәрлекләрен аренда түләве һәм алардан файдалану буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тану турында документларны исәпкә алуны һәм саклауны тәэмин итә (җирле бюджетка керем өлешендә).

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы территориясендә
урнашкан муниципаль мөлкәттән һәм җир
кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда
түләве һәм пеня буенча әҗәтләрне түләтүгә
һәм исәптән  чыгаруга карата ышанычсыз
дип тану Тәртибенә (җирле бюджетка
керем өлешендә) кушымта №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт  мөнәсәбәтләре палатасы
Бланкы

Муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен файдаланган өчен аренда түләве буенча исәптән чыгарылырга тиешле бурыч суммасы турында
БЕЛЕШМӘ
________________________________________________________
(Оешманың, физик затның тулы аталышы)

20_____ елның ___   ___________булган торыш буенча

| № п/п | Аренда түләүләренең төре | Аренда түләве буенча әҗәт | Пенялар буенча әҗәт | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |
| | Барысы: | | | |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт  мөнәсәбәтләре палатасы
рәисе
______________ __________________________
(Имза)           (Ф.И.А.и.)